КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 27 август г.Казань № 640

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда сәнәгать предприятиеләренең яңа җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 27 сентябрь, 1188 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда сәнәгать предприятиеләренең яңа җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2023 ел, 27 сентябрь, 1188 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 13 июль, 554 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2024» саннарын «2025» саннарына алмаштырырга;

1 пунктта «2024» саннарын «2025» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2024 елда сәнәгать предприятиеләренең яңа җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «2024» саннарын «2025» саннарына алмаштырырга;

1.1 пунктта «2024» саннарын «2025» саннарына алмаштырырга;

5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яңа җиһазлар - «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә сәнәгатьнең дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган Россия сәнәгать продукциясе реестрына кертелгән Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча продукциянең гомумроссия классификаторы нигезендә 26, 27 һәм 28 классларга (28.3 ярдәмче класстан тыш) кертелгән һәм урнашу урыны Татарстан Республикасы булган Россия сәнәгать продукциясе;»;

1.3 пунктта «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 116-ТРЗ номерлы» сүзләрен «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктның икенче абзацында «2022 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган» сүзләрен «2023 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк булмаган» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктның җиденче абзацында «2026 елның 31 декабре» сүзләрен «2027 елның 31 декабре» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«сайлап алуда катнашучы тарафыннан сайлап алу елында «Сәнәгать предприятиеләренә җиһазларның Россия лизинг оешмалары белән лизинг шартнамәсе (шартнамәләре) төзегәндә беренче кертемне (аванс) түләүгә чыгымнар өлешен каплау» Программасы чарасы буенча гариза бирелмәгән;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 1.5 пунктындагы җиденче абзацында күрсәтелгән датага кадәр җиһазлар алынмаган.»;

3.1 пунктка «заявкалар бирә башлау датасына кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«3.3. Сайлап алуны уздыру турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге Тәртипнең 3.1 һәм 3.2 пунктларында билгеләнгән сайлап алуны уздыру турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә 3 календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 5.7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.»;

4.2 пунктта «Гамәлдән чыгару турында игълан» сүзләренә кадәр «Үткәрүне» сүзен өстәргә;

5.3 пунктта:

«б» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле ««н» – «п» пунктчалары өстәргә:

«н) әлеге Тәртипнең 1.5 пунктының җиденче абзацында күрсәтелгән датага кадәр җиһазларны алмауны раслый торган гарантияле хат;

о) сайлап алуны үткәрү аеның 1 нче көненә бирелгән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә танылканган Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

п) сайлап алуда катнашу өчен гариза бирелгән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча алынган җиһазларга Россия сәнәгать продукциясе реестрыннан өземтә;»;

түбәндәге эчтәлекле $6.3^1$ пункт өстәргә:

«$6.3^1$. Заявкаларны тулы, һәрьяклап һәм объектив карау һәм бәяләү максатларында үзләре тапшырган документлар һәм мәгълүмат буенча аңлатмалар алу өчен сайлап алуда катнашучыдан мәгълүмат һәм документлар алырга кирәк булган очракта Министрлык «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, документлар һәм мәгълүматка карата аңлатуны сайлап алуда катнашучыдан соратып ала, кирәк булса, сайлауда барлык катнашучыларга бертигез дәрәҗәдә җибәрелә.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауда Министрлык сайлап алуда катнашучылар тарафыннан документларга һәм мәгүлүматка карата аңлатма бирү срогын билгели, әлеге срок тиешле рәсми сорау урнаштырылган көннән соң килә торган көннән кимендә ике эш көнен тәшкил итәргә тиеш.

Сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның икенче абзацы нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле рәсми сорауда билгеләнгән сроклар эчендә әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә соратыла торган мәгълүматны һәм документларны булдыра һәм «Электрон бюджет» системасына бирә.

Әгәр сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп соратыла торган документларны һәм мәгълүматны, әлеге пунктның икенче абзацы нигезләмәләрен исәпкә алып, тиешле рәсми сорауда билгеләнгән срокта тапшырмаган булса, бу турыда мәгълүмат әлеге Тәртипнең 6.15 пунктында каралган заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенә кертелә.»;

6.5 пунктта татар текстында «комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы» сүзләрен «комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта:

татар текстында «комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы» сүзләрен «комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән заявкаларны карап тикшерү беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.12. Комиссия заявкаларны ранжировкалау барышында комиссия заявкаларны бәяләү, гомуми бәяләүдә аларның үлчәү күрсәткечләрен билгеләү, заявканың йомгаклау рейтингын билгеләү, субсидия бирү нәтиҗәләренең планлаштырылган күрсәткечләрен Программаның тиешле чарасының нәтиҗәлелеге күрсәткечләре белән чагыштыру гамәлгә ашырыла.

Рейтингка кертелгән заявкалар зуррак әһәмияттән түбәнрәк әһәмияткә бәяләүнең түбәндәге критерийлары буенча бәяләнә:

R1 – Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамаган эшчәнлек төрләреннән тыш, Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре буенча яңа кыйммәт булдыру (яңа төп фондларны гамәлгә кертү, модернизацияләү, реконструкцияләү) хисабына хисап елы өчен төп фондларның тулы исәпкә алу кыйммәтен арттыруны (керүне) (тупланган нәтиҗә белән) («Төп фондларның (акчаның) һәм финанс булмаган башка активларның хәрәкәте булу-булмавы турында мәгълүматлар» дигән 11 нче федераль статистик күзәтү формасының 4 графасындагы 07 нче юлы) соратылган субсидия күләменә карата;

R2 – соратылган субсидия күләменә карата икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча төп капиталга инвестицияләр күләме мөнәсәбәте (тупланган нәтиҗә белән);

R3 – соратылган субсидия күләменә карата икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча үзләре җитештереп, төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләме мөнәсәбәте (тупланган нәтиҗә белән).

Заявкаларны иртәләү заявкада планлаштырыла торган субсидияләр бирү нәтиҗәләреннән чыгып һәм әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә субсидия бирү елыннан башлап өч эзлекле ел йомгаклары буенча исәпләнә торган һәр критерий буенча аерым гамәлгә ашырыла.

Заявкаларга һәр бәяләү критерие буенча баллар бирелә ($U1_i$, $U2_i$, $U3_i$), монда i-заявкаларны теркәгәндә бирелгән заявканың тәртип номеры.

Заявкаларны комиссия тарафыннан бәяләгәндә һәр критерий буенча баллар әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә бирелә.

Заявка балларының ахыргы саны ($Uнәтиҗә_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Uитог_i = U1_i \times \frac{k1}{100} + U2_i \times \frac{k2}{100} + U3_i \times \frac{k3}{100},$$

монда k - саллы әһәмияте (процентларда):

k1 = 20,

k2 = 35,

k3 = 45.

Заявкаларның йомгаклау рейтингы (Rитог) балларның йомгаклау санын киметү һәм алынган баллар саны тигезләнгән очракта заявка керү чиратлылыгы тәртибендә төзелә. Рейтингта беренче урын иң күп балл җыйган заявкага бирелә. Сайлап алуның башка катнашучыларына аларның рейтингтагы заявкаларының номерларына туры килә торган урыннар бирелә.»;

7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.15. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү нәтиҗәләре нигезендә бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында комиссия рәисенең һәм комиссия әгъзаларының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук, аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда урнаштырыла.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, мондый үзгәрешләр кертелү сәбәпләре күрсәтелеп, әлеге пунктта билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең яңа версиясенә имза куелган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе аңа имза куелган көннән алып өч эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

7.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.9. Килешү төзелгән көннән алып биш эш көне эчендә Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында йә әлеге Тәртипнең 7.8 пунктында каралган нигезләрдә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә, ул Министрлык җитәкчесе (яисә ул вәкаләт биргән зат) тарафыннан раслана.

Министрлык субсидия алучыларга субсидияләр бирүне субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килүче 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидияләр алучыларга Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмалары учреждениеләрендә (әгәр Россия Федерациясе бюджет законнары белән башкасы билгеләнмәгән булса) ачылган исәп-хисап яисә корреспондент счетларына заявка составында күрсәтелгән реквизитлар буенча күчерә.»;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин